**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе**
**“В.Ф.Тарасов исемендәге Иске Мукшы урта гомуми белем бирү мәктәбе”**

| **«Раслыйм»** | **«Килешенде»** | **«Килешенде»** |
| --- | --- | --- |
| Директор: ________ Шәрәфетдинов Р.Г.<br><br>Боерык № <br>«28 » август 2014 нче ел. | Уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары : ____________Козлова Н.В.<br><br>«28» август 2014 нче ел. | Методик берләшмә житәкчесе: ________Шәрәфетдинова Г.Ф<br><br>Беркетмә № __1_<br>«25» август 2014 нче ел. |

**10 нчы “А” сыйныфы өчен татар теленнән эш программасы**
**(рус төркеме)**
Төзүче: югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Шәрәфетдинова Гүзәл Фәсхетдин кызы

Педогогик киңәшмә
утырышында каралды.
Боерык № 1

2014-2015 нче уку елы

**Татар теленнән эш программасы**
**10 нчы сыйныф (татар төркеме)**
**(35 сәг)**

**Аңлатма язуы**

**Эш программасы статусы**.

Әлеге эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелгән:

1 . “Мәгариф турында” Россия Федерациясенең Законы
2. “Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законы
3. “2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы” (№794 от 25.10.2013)

4. Татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты.-ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан , 2008

5.“Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары” на (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова,В.А. Гарипова, Р.Р. Җамалетдинов, Р.Ф.Җамалетдинова. 1- 11 нче сыйныфлар. - Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2010),
6.. 2014/2015 нче уку елында татар телен укыту үзенчәлекләре.(Методик тәкъдимнәр)

7..Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының МБГБУ“В.Ф.Тарасов исемендәге Иске Мукшы урта гомуми белем бирү мәктәбе” нең уку планы (Уку планы буенча боерык №179 1нче сентябрь 2014 нче ел)
8.Дәреслек:Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек.Авторлары: Р.С.Абдуллина, Г.М.Шәйхиева Казан, 2012.
.

***Эш программасы структурасы.***

Татар теленнән эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән.

***Эш программасының эчтәлеге.***

Яңа стандарттагы иң мөһим таләп мондый: мәктәпне тәмамлаганда, «укучы үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш”. Бу – яңа стандартта эшлекле белем дип атала. Эшлекле белем – стандарт керткән яңалыкның әһәмиятле эчтәлеген ачып бирүче иң гомуми төшенчә. Белем алу гамәлләренең структурасын һәм принцибын стандарт үзе аңлата:

Татар теле укытуның максатлары:
укучыларда гражданлык һәм патриотик хисләр тәрбияләү;
укучыларга татар халкына хас булган рухи, әхлакый, мәдәни төшенчәләр турында мәгълүмат бирү;
татар теленең эчке үзенчәлекләренә төшендерү;

ана телендә аралаша белү культурасын тәрбияләү һәм аны үстерү;
татар телен иҗтимагый күренеш буларак аңлау, шушы тел нормаларын саклап, татар телендә тормышның төрле ситуацияләренә бәйле рәвештә аралаша-аңлаша белү;
тел берәмлекләрен танып, аларны тикшерә, чагыштыра алу һәм аралашуда урынлы куллану күнекмәләрен камилләштерү;
текст белән эшләү, аннан кирәкле мәгълүматны ала белү һәм аны тиешенчә үзгәртә алу күнекмәләрен үстерү;
ана теленнән алган белем һәм күнекмәләрне укучыларның үз сөйләмендә куллана алуларына ирешү;
дәресләрдә алган белемнәрне аралашуның төрле өлкәләрендә урынлы һәм дөрес итеп куллана белү;
укучыларның орфографик һәм пунктацион грамоталыгын үстерү.

***Белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы.***

- ***Коммуникатив компетенция***. Сөйләмдә аралашу өлкәләре һәм ситуацияләр. Сөйләм ситуацияләрен тәшкил итә торган берәмлекләр.
- Сөйләм эшчәнлеге төрләрен (тыңлап аңлау, сөйләү, уку һәм язу) камилләштерүне дәвам итү;
- Аралашуның төрле өлкәсенә караган диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү
- Текстның төренә карап, аны төрлечә уку күнекмәләрен камилләштерү.
- Тәкъдим ителгән текстны мәгълүмати әһәмияте ягыннан үзгәртү.
- Фәнни, рәсми эш, публицистик, сөйләм һәм матур әдәбият стильләре, аларның үзенчәлекләре.
- Фәнни һәм рәсми аралашуның телдән һәм язма формаларын куллану.доклад, реферат, тезис., бәяләмә, алу кәгазе, ышаныч кәгазе, резюме
- кебек төрле жанрдагы зш кәгазьләрен язу күнекмәләрен камилләштерү.
- Сөйләм әдәбе нормалары.

- ***Лингвистик компетенция.*** Телнең кеше тормышында һәм җәмгыятьтә тоткан урыны. Татар теле – Татарстан Республикасының дәүләт теле. Татар теле – татар халкының милли теле.
- Матур әдәбият һәм аның нормалары турында төшенчә.
- Татар теленең үсештә булуы. Соңгы елларда татар теле лексикасындагы үзгәрешләр.
- Тел белеменә караган сүзлекләр һәм алардан файдалану.

***Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:***

1. телнең төп функцияләрен белү;
2. “сөйләм ситуациясе”, “әдәби тел”, “тел нормасы”, “сөйләм культурасы” төшенчәләренең мәгънәләрен аңлау;.
3. тел берәмлекләрен һәм ярусларын, аларның төп билгеләрен һәм үзара бәйләнешләрен белү;
4. татар әдәби теленең орфоэпик, лексик, грамматик, орфографик,һәм пунктацион нормаларын белү;
5. тормыш-көнкүреш, иҗтимагый-мәдәни, фәнни-уку, рәсми эш стильләрен, аларга бәйле булган сөйләм әдәбе нормаларын белү;
6. телдән һәм язмача белдерелгән төрле фикерләргә эчтәлеге һәм формасы ягыннан чыгып бәя бирү;
7. текстка лингвистик анализ ясау;
8. тел белән халык тарихы, мәдәнияты тыгыз бәйләнгән булуын аңлау;
9. текстның жанрына карап, аны төрлечә (танышу, өйрәнү, реферативхарактерда һ.б.) уку;
10. кирәкле мәгълүматны төрле чыганаклардан (фәнни текстлардан, белешмә әдәбияттан, компакт дисктан, Интернеттан) алу;

11. телдән һәм язмача бирелгән текстны мәгълүмати яктан эшкәртүнең төрле алымнарын файдалану;
12. тормыш-көнкүреш, фәнни, рәсми текстларны монологик һәм диалогик характерда, төрле жанрда һәм стильдә язу;
13. телдән һәм язма сөйләмдә татар әдәби теленең орфоэпик, лексик, грамматик нормаларын саклау;
14. аралашуның төрле өлкәләрендә сөйләм әдәбе нормаларын саклау;
15. язуда хәзерге татар здзби теленең орфографик һәм пунктацион нормаларын саклау;
16. сөйләмдә һәм язуда татар әдәби теленә хас булган сүз тәртибен саклау;
17. татар әдәби телендә төрле ситуацияләрдә телдән һәм язма аралаша белү;
18. төрле жанрда һәм стильдә язылган (сөйләнгән) текстны татар теленә рус теленнән, рус теленә татар теленнән тәрҗемә итә белү.

## Календарь-тематик планы

| № | Дәрес темасы | Сәгать саны | Дәрес тибы | Укучылар эшчәнлегенең характеристикасы яки уку эшчәнлегенең төрләре. деятельности | Тикшерү | Өй эше | Үткәрү вакыты | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | План | Факт | |
| 1 | Тел-аралашу чарасы, иҗтимагый һәм сәяси күренеш | 1 | катнаш | | Сорауларга җавап | Пар. 1-4. 10нчы күнегү. | 04.09 | | |
| 2 | Татар теле белеменең төп тармаклары | 1 | катнаш | әңгәмә | Сорау-җавап | Сор. җав. бир. 20 бит | 11.09 | | |
| 3 | Тел һәм сөйләм | 1 | Яңа материалны өйрәнү | Күнегүләр | Сорау-җавап | Алынма сүзләр.16, 17нче күнегү | 18.09 | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Тел- шартлы билгеләр системасы | 1 | Катнаш | мисаллар | Сораулар | Сор. җав. бир 27 бит | 25.09 | | |
| 5 | Сөйләм үзенчәлекләре. Монологик һәм диа логик сөйләм | 1 | Белемнәрне гомумиләштерү, системалаштыру | күнегү | Мисаллар | 42нче күнегү | 02.10 | | |
| 6 | Диктант “Тормыш дәвам итә” | 1 | Контроль | Диктант язу | | Үткәннәрне кабатларга | 09.10 | | |
| 7 | Интонация. Басым. Пауза. | 1 | Яңа материалны өйрәнү | Күнегүләр | | 96нчы күнегү | 16.10 | | |
| 8 | Сүзне оештыручы иҗек басымы | 1 | Яңа материалны өйрәнү | Күнегүләр | Әйттерү | 93нче күнегү | 23.10 | | |
| 9 | Аваз һәм хәреф. Транскрипция. Сузык һәм тартык авазлар | 1 | Белем-не гомумиләштерү, систем-у | күнегү | Кабатлап карау | 47нче күнегү | 30.10 | | |
| 10 | Аваз үзгәрешләре. Сузык авазлар үзгәреше. | 1 | Белем-не гомум-рү, систем-ру | күнегү | Мисаллар әйтү | 54,59 нчы күнегү | 13.11 | | |
| 11 | Тартык авазлар үзгәреше. Тартык авазлар охшашлану. | 1 | Белем-не гомуми-ү, систем-ру Яңа матер-ны өйрәнү | Күнегүләр уку | әйттереп карау күнегүләрне уку | 83 нче күнегү 74 нче күнегү | 20.11 | | |
| 12 | Тартыкларның чиратлашуы. | 1 | Яңа матер-ны өйрәнү | мисаллар | Күнегүләр | 85 нче күнегү | 27.11 | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 13 | Диктант (контроль) “Ипекәй” | 1 | Контроль | Диктант язу | | Үткәннәрне кабатларга | 04.12 | | |
| 14 | Орфоэпия. | 1 | Белем-не гомумил-рү, системал-ру | Күнегүләр | Сорау-җавап | 105нче күнегү | 11.12 | | |
| 15 | Орфография | 1 | Белем-не гомумиләш-рү, систем-рума-ру | Күнегү эшләү | Сораулар бирү | 116нчы күнегү. Сор. җав. бир | 18.12 | | |
| 16 | Изложение үтәрклмәгән | 1 | Контроль | | | Үткәннәрне кабатлау | 25.12 | | |
| 17 | Лексика. Синонимнар. | 1 | Белем-не гомумил-рү, систем-ру | Күнегү | Күнегүләр | 124 нче күнегү | 15.01 | | |
| 18 | Антонимнар ИЗЛО | 1 | Белем-не гомум-рү, систем-ру | Күнегүләр | | 130 нчы күнегү | 22.01 | | |
| 19 | Күп мәгънәле сүзләр. | 1 | Яңа матер-ны өйрәтү | мисаллар | | 138нче күнегү | 29.01 | | |
| 20 | Омонимнар. | 1 | Белем-не гомум-рү, систем-ру | күнегү | Мисаллар | 142 нче күнегү | 05.02 | | |
| 21 | Охшаш яңгырашлы сүзләр | 1 | Яңа матер-ны өйрәнү | күнегү | | 149нчы күнегү | 12.02 | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 22 | Фразеология | 1 | Белем-не гомум-рү, систем-ру | Күнегүләр | Җөмләләрдә | 157 нче күнегү | 19.02 | | |
| 23 | Диктант “Гаилә балага нәрсә бирә?” | 1 | Контроль | | | Үткәннәрне кабатлау | 26.02 | | |
| 24 | Этимология. | 1 | Яңа материалны өйрәнү | күнегү | | 162 нче күнегү | 05.03 | | |
| 25 | Телнең сүзлек составы | 1 | Катнаш | күнегү | | 168 нче күнегү | 12.03 | | |
| 26 | Калькалар. | 1 | Яңа материалны өйрәнү | күнегү | Мисаллар китерү | 174 нче күнегү | 19.03 | | |
| 27 | Тарихи сүзләр, архаизм һәм неологизмнар. | 1 | Белем-не гомумил-рү систем-ру | Күнегүләр | Искә төшерү | 175нче күнегү | 02.04 | | |
| 28 | Лексикография | 1 | Катнаш | Сүзлекләр турында сөйләшү | | , 180 нче күн. Сөйли белергә | 09.04 | | |
| 29 | Контр. изложение | 1 | | | | Үткәннәрне кабатларга. | 16.04 | | |
| 30 | Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы.Сүзнең тамыры һәм нигезе. | | Кабатлау. | Күнегүләр. | | 186 нчы күнегү. | 23.04 | | |
| 31 | Сүз ясалу ысуллары. | | Кабатлау. | Күнегүләр. | | 210,204 күнегүләр. | 30.04 | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 32 | Татар һәм рус сүзләрендә сүз төзелеше. | | Яңа материалны өйрәнү | Күнегүләр | | 220 нче күнегү. | 07.05 | | |
| 33 | Контроль диктант. “Аналар һаман юксына” | | | | | Үткәннәрне кабатларга. | 14.05 | | |
| 34-35 | 10 нчы сыйныфта үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау | 1 | Катнаш | Тест сорауларына җавап | Тест нәтиҗәләре | Тест сорауларына җавап бирергә | 21.05 28.05 | | |
| | Барысы | 35 | | | | | | | |

## Язма эшләрнең күләме һәм аларны бәяләү

Укучыларның тел һәм сөйләм материалын үзләштерү дәрәҗәсен яки аларның гомуми грамоталылыгын диктант, изложение, сочинение яздырып тикшереп була. Моннан тыш, сорауларга язма рәвештә җавап алу да уңай нәтиҗә бирә. Сораулар укыган әсәр, аерым текст, рәсем яки караган фильмнар буенча тәкъдим ителә. Бу очракта язма эшнең күләме һәр сыйныфның изложение күләменнән артмый. Укытучы эшне бәяләгәндә, түбәндәге таләпләрне истә тотарга тиеш: җавапның тулы, төгәл, дөрес булуы, сөйләмне стилистик яктан камиллеге, орфографик һәм пунктуацион яктан грамоталылыгы.

***Сорауларга җавап язуны бәяләү:***

1. Барлык сорауларга да дөрес җавап бирелсә, «5» ле куела (бер сөйләм хатасы яки бер пунктуацион хата булырга мөмкин).
2. орауларга дөрес җавап бирелсә, ләкин ике сөйләм хатасы, өч орфографик, ике пунктуацион хата яки ике сорауга җавап язганда төгәлсезлек җибәрелсә, «4» ле куела.
3. Язма эштә сорауларга җавап бирә белү күнекмәләре сизелсә, өч сөйләм хатасы, дүрт орфографик, биш пунктуацион хата булса, «3» ле куела.
4. Җавапларның яртысы дөрес булмаса, сөйләм хаталары өчтән артса, биш орфографик, алты пунктуацион хатасы булса, «2» ле куела.

## Язма эшләрнең күләме

| **Сыйныф** | **Эш төрләре** | | | |
|---|---|---|---|---|
| | **Сочинение** | **Диктант** | **Изложение** | **Барлыгы** |
| X | 6(2) | 4(2) | 2(1) | 12(1) |

***Искәрмә. Җәя эчендә контроль характердагы эшләр саны күрсәтелде.***

## Диктантларның күләме һәм аларны бәяләү

Диктант — укучының гомуми грамоталылыгын тикшерү өчен уздырыла торган язма эшнең бер төре. Диктантлар берничә төрле була: сүзлек диктанты, өйрәтү диктанты, искәртмәле, аңлатмалы, сайланма, иҗади, күрмә, хәтер, ирекле диктантлар.

1. Орфографик хатасы булмаса, «5» ле куела (бер пунктуацион хата булырга мөмкин).
2. Бер орфографик, бер пунктуацион хатасы булса, «4» ле куела.
3. Ике орфографик, ике пунктуацион хатасы булса, «3» ле куела.

4. Биш орфографик, дүрт—алты пунктуацион хатасы булса, «2» ле куела.

**Контроль диктантларның күләме һәм аларны бәяләү**

Алган белем һәм күнекмәләрне тикшерү өчен, контроль диктантлар елга ике тапкыр яздырыла.

**Контроль диктантның күләме**

| Ел вакыты | Сүз саны |
|---|---|
| | X |
| **Уку елы башында** | 120—130 |
| **Уку елы ахырында** | 125—135 |

Контроль диктант текстлары үз эченә өйрәтелгән тема яки темалар буенча орфограмма һәм пунктограммаларны (2—3 очрак) ала. Грамматик биремле диктант булганда, сүз саны киметелә дә ала. Контроль диктантта укучы тарафыннан төзәтүләр күп булса, билге бер баллга төшәргә мөмкин.

***Контроль диктантны бәяләү***

1. Эш пөхтә башкарылса, хатасы булмаса «5» ле куела. (Бер — орфографик, ике пунктуацион хата булырга мөмкин.)
2. Ике орфографик, ике пунктуацион яки бер орфографик, дүрт пунктуацион хаталы эшкә «4» ле куела.
3. Дүрт орфографик, дүрт пунктуацион яки өч орфографик, алты пунктуацион хаталы эшкә «3» ле куела.
4. Алты орфографик, биш пунктуацион яки биш орфографик, сигез пунктуацион хаталы эшкә «2» ле куела.

**Изложениенең күләме һәм аны бәяләү**

Изложение яздыру өчен, матур әдәбият әсәрләреннән өзекләр, хикәяләр, аерым текстлар алына. Алар эчтәлеге һәм күләме ягыннан тиешле сыйныф таләпләренә җавап бирергә, тәрбияви максатларны үз эченә алырга һәм бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү, камилләштерү юнәлешендә булырга тиеш. Изложение ярдәмендә укучының тема эчтәлеген ача белү осталыгы, лексик байлыгы, орфография, грамматика, пунктуация өлкәсенә караган грамоталылыгы тикшерелә. Бу вакытта яңа сүзләр һәм тәгъбирләрне аңлатырга һәм аларны тактага язып куярга кирәк.

## <u>Изложение текстының күләме</u>

| Сыйныф | Уку елы башы | | Уку елы ахыры | |
|---|---|---|---|---|
| | Сүз саны | Язма күләме | Сүз саны | Язма күләме |
| X | 390—410 | 145—155 | 410—430 | 155—165 |

Изложениене бәяләгәндә, фикерләрнең логик эзлеклелегенә, эчтәлекнең тулы, дөрес бирелүенә, язма сөйләм теленең камиллегенә, грамоталы итеп яза алу дәрәҗәсенә игътибар ителә. Изложение һәм сочинениегә ике төрле билге куела. Берсе— эчтәлек, сөйләмне дөрес оештыра алу өчен, икенче — грамоталылыкка.

### *Изложениене бәяләү*

1. Тема тулысынча ачылган, фактик һәм техник хаталары булмаган, стиль бердәмлеге сакланган эшкә «5» ле куела. (Бер орфографик, ике пунктуацион яки ике грамматик хатасы булырга мөмкин.);
2. Текстның эчтәлеге темага нигездә туры килсә, фикерне белдерүдә зур булмаган ялгышлыклар җибәрелсә, бер-ике фактик, бер-ике техник хатасы булса, ике орфографик, ике-өч пунктуацион, бер грамматик хатасы булган эшкә «4» ле куела;
3. Язмада эчтәлек эзлекле бирелмәсә, стиль бердәмлеге сакланмаса, өч фактик, ике-өч техник хатасы булса, өч орфографик, дүрт пунктуацион, ике грамматик хатасы булган эшкә «3» ле куела;
4. Эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаса, язма эш планга туры килмәсә, фактик һәм техник хаталары күп булса, орфографик хаталарның саны дүрттән, пунктуацион хаталарның саны биштән, грамматик хаталар саны өчтән артса, «2» ле куела.

## <u>Сочинениенең күләме һәм аны бәяләү</u>

Иҗади эшнең бер төре буларак, сочинение — укучының язма рәвештә үти торган эше. Ул бәйләнешле сөйләм үстерү күнекмәләре булдыруда зур әһәмияткә ия.
Әдәби (хикәяләү, очерк, истәлек, хат, рецензия һ.б.), әдәби-иҗади, өйрәтү характерындагы, ирекле, рәсемнәр нигезендә үткәрелә торган һәм контроль сочинениеләр була.
Сочинение план нигезендә языла. Ике сәгать дәвамында сыйныфта язылган *сочинениенең күләме* 1-2 бит булырга тиеш.

### <u>*Сочинениене бәяләү*</u>

1.Язманың эчтәлеге темага тулысынча туры килсә, фактик ялгышлары булмаса, бай телдә, образлы итеп язылса, стиль бердәмлеге сакланса, «5» ле куела. (Бер орфографик яисә ике пунктуацион (грамматик) хата булырга мөмкин.)

2.Язманың эчтәлеге нигездә темага туры килсә, хикәяләүдә зур булмаган ялгышлыклар күзәтелсә, бер-ике фактик хата җибәрелсә, теле бай, стиль ягы камил булып, ике орфографик, өч пунктуацион (грамматик) яисә бер-ике сөйләм ялгышы булса, «4» ле куела.
3. Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлар, аерым фактик төгәлсезлекләр булса, хикәяләүдә эзлеклелек югалса, сүзлек байлыгы ярлы булса, стиль бердәмлеге дөрес сакланмаган җөмләләр очраса, өч орфографик, дүрт пунктуацион (грамматик) яисә өч-дүрт сөйләм хатасы булса, «3» ле куела.
4. Язма темага туры килмичә, фактик төгәлсезлекләр күп булып, план нигезендә язылмаса, сүзлек байлыгы бик ярлы булса, текст кыска һәм бер типтагы җөмләләрдән торып, сүзләр дөрес кулланылмаса, стиль бердәмлеге сакланмаса, биш орфографик, сигез пунктуацион (грамматик) яисә дүрт — алты сөйләм хатасы булса, «2» ле куела.
Татар урта мәктәпләре өчен татар теле программаларында диктант, изложение һәм сочинение яздыруга куелган таләпләр, нигездә, рус мәктәбендә укучы татар балаларына да туры килә.

**Укыту- методик комплекты**

1. Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары. 1 -11 сыйныфлар. (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова,В.А. Гарипова, Р.Р. Җамалетдинов, Р.Ф.Җамалетдинова. Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2012 )
2. Татар телен өйрәнү өчен Р.С.Абдуллина һәм Г.М.Шәйхиеваның 2012 нче елда үзгәрешләр белән “Мәгариф” нәшриятында басылган дәреслеге файдаланыла.
3. Татар теле морфологиясе. Ф.М. Хисамова. –Казан, “Мәгариф”, 2005.
4. Хәзерге татар әдәби теле. Ф.С. Сафиуллина, М.З.Зәкиев. Казан, “Мәгариф”, 1994.
**5.2014-2015 нче уку елында татар телен үзенчәлекләре(методик тәкъдимнәр) Казан, 2014**

10 нчы сыйныф
Рус мәктәпләренең
татар  төркемнәре өчен
2014-2015нче уку елы

**Диктант**
**Тормыш дәвам итә**

Мусалар юк инде...

Ә җирдә тормыш дәвам итә, көн була да төн җитә, күктә болытлар агыла да агыла. Хәзер аларга бүтән шагыйрьләр карый. Аларда мәңгелек хәрәкәт белән мәңгелек сер бар. Дөньяның бик күп шагыйрьләре аларны үзләренчә ачарга тырышкан, әмма ачып бетерә алмаган.

Муса да аларга, нәүмизләнеп, озак-озак карап торган. Нәрсәләр күргән, нәрсәләр ачкан ул аларда? Моны инде кешеләргә аның шигырьләре генә сөйләр. Тик алар әле юлда, ә юллары бик-бик озак, бәлки әле тагын төрмәләргә керерләр, концентрацион лагерьларда булырлар, француз партизаннары арасында азатлык өчен көрәшеп йөрерләр, ә сугыш беткәч, батыр солдатлар кебек, илләр һәм чикләр аша туган якка – Идел буйларына кайтырлар. Аларны анда сагынып көтәләр бит. (106 сүз)                    (Г.Әпсәләмовтан)

**Диктант**
**Ипекәй**

Бала , теле ачылганда, иң тәү башлап нинди сүзне әйтә:”әннә” диме, әллә “мәм-мәм” дип әйтәме? Кайсын гына башлап әйтмәсен,бу ике сүз-адәм баласының иң беренче сүзләре, шушы сүзләр белән аның теле ачыла. Ана һәм ризык. Ризык – адәм баласы өчен ана шикелле үк зарури, иң кадерле нәрсә. Ана -җан бирүче, ә ризык- яшәтүче.ана белән ризыктан башка Җир йөзендә тереклек булмас иде. Күрәсез, бу ике төшенчәнең мәгънәсе һәм әһәмияте никадәр зур.

Ризык дигәнебез,- барыннан да элек, икмәк ул. Икмәк барлык ризыклардан өстен тора, бик күп, бик күп ризыклар икмәктән башалана. Иртәнге чәй өстәлен генә күз алдына китерик., бар да шул икмәк аркасында өстәлгә килгән ризыклар бит.

Икмәк бөтен байлыклардан да кирәгрәк, кыйммәтлерәк нәрсә икән.. Икмәк булмаса бөтен нәрсәнең иң затлы кием-салымнарның, иң кадерле әйберләрнең дә кыйммәте бетә, алар чүпкә әйләнә.

Икмәк кешегә иң зарури ризык итеп кенә түгел, ә илнең иң зур байлыгы, дәүләтнең төп куәте дип тә санала. Чыннан да, илдә,дәүләт кулында икмәк җитәрлек булмаса, халык тук , бөтен яши алыр идемени, дәүләт башка байлыкларын, бүтән ихтыяҗларга тота алыр идемени! (140 сүз) ( Ә.Еникидән)

Контроль диктант

**Гаилә балага нәрсә бирә?**

Әйбәт гаилә балаларга нәрсә бирә ала? Барыннан да элек, ул сабыйлыкның алтын чорын бүләк итә, ә бу, мөгаен, бөтен гомернең иң бәхетле чорыдыр. Сабый чак – кеше гомеренең кабатланмас бер чоры, һәм гаилә сабыйлар үсешендә искиткеч зур роль уйный.

Үсемлекнең тиешенчә үсүе өчен, кояш нуры кирәк булган кебек, балага да әти-әни мәхәббәтенең яктысы кирәк. Нәкъ менә шул мәхәббәт һәм ата-ананың шәхси тәрбиясе – кешене кеше итә торган төп этәргеч.

Нәкъ менә гаиләдә, мәктәпкә кадәрге чорда, шәхеснең иң мөһим психологик нигезләре барлыкка килә. Шул вакытта безнең психикабызның иң озын гомерле сыйфатлары, тормышка эмоциональ һәм әхлакый мөнәсәбәтнең нигезләре өлгерә башлый. Соңрак алар өстенә тормышның башка йогынтылары катлам-катлам булып урнашачак, әмма әлеге йогынтыларны үзләштерү, аларны үз гамәлләреңнең этәргеченә әверелдерү – болар барысы да бала шәхесенең гаиләдә салынган төп нигезенә бәйле булачак.

Ата –аналар баланың рухи дөньясын формалаштыралар, дөньяны танып белергә, тормышны аңларга өйрәтәләр.Шуңа күрә гаиләдәге мәхәббәт, кешелекле мөнәсәбәтләр, җылы атмосфера – балага һава кебек үк кирәк нәрсәләр.

**Бирем: Соңгы абзацны сүз төркемнәре буенча тикшерергә.**

**Контроль диктант**

**Аналар һаман юксына.**

Хәтер... Ана тәрәзә янына баскан да тирән уйга чумган... Ул иң чиста, иң матур күлмәген кигән, башына бизәкле ал яулыгын бәйләгән, гәрәбә муенсасын таккан. Дивардагы сәгать вакытны саный. Җитмеш ел буена, минутларны һәм сәгатьләрне барлый ул. Өстәлдә саргайган өчпочмаклы солдат хатлары ята.Диварда улының рәсеме эленеп тора.Ананың баласыннан шушы кдерле истәлекләр генә калган.

Хәсрәтле уйларга талаган, хәтер диңгезендә йөзә ана. Улының фронтка киткәнен бүгенгедәй хәтерли ул.

Әнә, чаналы ат, урамны артта калдырып, каршыдагы сөзәк тауга менеп юлга чыкты..Егет ашыкмый гына чана артыннан атлый. Туктый да, авлына борылып, яңгыравыклы тавышы белән җырлап җибәрә. : “Бу китүдән кайта алмасак, сау булыгыз, туганнар!”Ана бу җырны көн саен күңеленнән көйли.

Әйе, аналар күңеле беркайчан да картаймый. Ул еллар үткән саен, һаман нечкәрә, һаман сафлана гына бара. Аналарның хәтерләре дә кайнап типкән чишмә башы кебек. (133 сүз) (К.Төхәветдиновтан)

**Бирем. 1. Чиста, кебек, кадерле, сүзләренең синонимнарын табып язарга.**
**2. Хәсрәтле, истәлекләр, ашыкмый сүзренең синонимнарын табып язарга.**